БӘЙРӘМ УЗГАЧ

Татарстанда Яңа ел ялларын ниләр белән истә калган?

> 2

ТАШЛЫК ЕГЕТЕ

Разил Вәлиевнең без белгән һәм белмәгән сыйфатлары

> 3

ҖИҢЕЛ ПАР БЕЛӘН!

Саба егетен башка районнарга мунча керергә чакыралар

> 4

КӨЧЛЕ РУХЛЫЛАР

Авариядән соң Илназ Мәхмүтовның тормышы көрәшкә әверелә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 3 (28776) | Чәршәмбе | 12 гыйнвар | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Яңалык

Авыл җирендә эшләүче фельдшерлар хәзер халыкны дәвалап кына калмыйча, дару да сатачак. Быелның 1 гыйнварыннан Россиядә шундый закон үз көченә керде. Бу яңалык үзендә даруханәсе булмаган авылларга кагыла. Хәзер фельдшерлар, кешене дәвалап, кирәкле даруын язып кына калмыйча, шул даруны үзе үк сата да булып чыга. Моңа кадәр исә бу эш белән фармацевтлар гына шөгыльләнә ала иде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ТӨЙМӘСЕЗ БУЛМЫЙ

АВЫЛДА ЭШЛӘҮЧЕ ФЕЛЬДШЕРЛАР ДАРУ САТА БАШЛАЯЧАК

«Даруханәсе булмаган авыл җирлегендә урнашкан фельдшер-акушерлык пункты, амбулатория, гомуми практика табибы үзәкләрендә эшләгән медицина хезмәткәрләре дару сата алачак», – диелә Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы хәбәрендә. Яңа закон нигезендә дару сату өчен бирелә торган лицензия алу вакыты да кыскара. Шул бер лицензия белән авыл халкына медицина ярдәме күрсәтергә дә, дару сатарга да рөхсәт ителәчәк. Өстәмә документ артыннан йөрисе юк, кыскасы. «Лицензия алган оешмада эшләгән медицина хезмәткәренең дарулар белән ваклап сату өлкәсендә өстәмә белеме барлыгын да расларга кирәкми», – диелә документта.

Бу яңалыкны ишетүгә, күптән кирәк иде, дип җиңел сулап куйгансыздыр. Адәм баласының кырыкмаса-кырык төрле чире бар бит. Сәламәтлек түгел, кәеф дигәнең аз гына үзгәрсә дә, төймә кабып куярга күнеккән без. Өстәвенә ике елдан бирле тормышыбызда коронавирус дигән зәхмәт котыра. Арабызда тиешле даруын алып кайтырга кеше таба алмый тилмергән ялгыз әби-бабайлар, район үзәгеннән ерак урнашкан яки анда барырга уйлаган очракта да юлы булмаган авыллар да шактый бит. Апас районының Коштаулы авылында яшәүчеләргә бу проблема яхшы таныш. Биредә, нигездә, өлкән яшьтәгеләр, пенсионерлар яши.

– Безнең авылда шәфкать туташы да, дару алып кайтучы да юк. Ә бит авылыбыз пенсионерлардан гына тора. Ковидтан соң авырыйм, укол салырга да кеше юк. Күптән түгел безгә күрше авылдан бер шәфкать туташын куйганнар иде. Ул: «Бер кеше өчен генә укол ясарга килмим», – диде. Тиешле ярдәмен күрсәтеп, даруын да сатсалар, без дә бик сөенер идек, әлбәттә, – дип сөйләде «ВТ» хәбәрчесенә шушы авылда яшәүче Гөлфия апа Әюпова.

Мамадыш районының Катмыш авылында яшәүче Зөлфия Гыйззәтуллина әлеге хәбәргә әллә ни аптырамады. «Бу безнең өчен яңалык түгел инде. Безнең фельдшер-акушерлык пунктында дарулар сатыла. Кирәген барасың да аласың. Фельдшер да, ялга китәсе булса, авылның «Ватсап»тагы төркеменә: «Дарулар килеп алыгыз», – дип яза. Кыйммәтле, сирәк кулланыла торган даруларны район үзәгенә барып яки бездән 12 чакрым ераклыктагы участок амбулаториясендә урнашкан даруханәдән алабыз», – ди ул.

Гомумроссия халык фронты (ОНФ) белгечләре якын арада авыл җирлекләре буйлап йөреп, җирле халыкның дарулар белән ни дәрәҗәдә тәэмин ителгәнлеген тикшереп чыкмакчы. Оешма җитәкчесе Михаил Кузнецов сүзләренә караганда, яңа закон Россия Президенты Владимир Путин белән «туры элемтә» вакытында халыктан килеп ирешкән мөрәҗәгатьләрдән соң кабул ителгән. Аерым алганда, Ростов, Ульяновск, Кострома, Самара, Липецк өлкәләрендә, Пермь, Ставрополь, Алтай краенда, Башкортстан авылларында яшәүчеләр, дару алу өчен, ун чакрым ераклыктагы район үзәгенә барырга туры килүеннән, анда илтүче автобусларның да сирәк йөрүеннән зарланган.

Саба районының Олы Шыңар фельдшер-акушерлык пункты фельдшеры Рузилә Мөхәммәтова авылда дару сату белән фельдшер түгел, махсус кеше шөгыльләнергә тиеш дигән фикердә. «Дару сату үзе – бер зур, мәшәкатьле эш. Аңа гел заказ биреп, кайтканын урнаштырып, хисабын алып барырга кирәк. Бер кешегә халыкка медицина ярдәме дә күрсәтү, аннан тыш шушы дару сату эшен дә алып бару бик авыр», – ди авылда 36 ел буе фельдшер булып эшләгән Рузилә ханым.

Олы Шыңар фельдшер-акушерлык пунктының да дару сатарга лицензиясе бар икән. Әмма касса аппараты булмагач, дару сатуны өлешчә туктатканнар.

– Даруханә булмаган авылларда даруны медпунктларда сатуга уңай карыйм. Авыл халкы өчен бик уңайлы бу. Ялгыз яшәгән, дару алып кайтып бирерлек кешесе булмаган әби-бабайларга бигрәк тә. Элегрәк бездә бөтен дару да бар иде. Киштә беркайчан да буш тормады. Дарулар бетә башлауга, яңадан алып кайтып куя идек. Хәзер даруны гариза буенча – кемгә күпме кирәк, шулкадәр күләмдә генә алып кайтабыз. Бу уңайсызрак, билгеле. Кешегә бит аңа гел бертөрле генә дару кирәкми. Бүген баш авыртканнан дару кирәк булса, иртәгә кул астында йөрәк авыртканнан даруы булмаска мөмкин. Гариза буенча гына кайтарткач, кирәк чакта гына медпунктта ул дарулар булмый, билгеле. Шуңа күрә авылдагы ФАП, медпунктларда салкын тигәндә, тамак авыртканда эчә, тынычландыра торган дарулар һәрчак сатуда булырга тиеш дип саныйм, – ди Рузилә ханым.

Авылдагы фельдшерларның эше арту белән аларның хезмәт хакы да артырмы? Әлегә бу сорау ачык кала. Һәрхәлдә, Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгында «ВТ» хәбәрчесенә бу уңайдан төгәл генә җавап бирүче булмады.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Россиядә яшәүче бер гаилә дарулар алуга елына уртача 19,5 мең сум акча сарыф итә икән. «Сбербанк иминиятләштерү» оешмасы тарафыннан уздырылган тикшеренү нәтиҗәләре шул хакта сөйли. Сораштыруда катнашучыларның яртысыннан артыгы (51 процент) аена берничә тапкыр дару сатып алуын, 24 проценты берничә айга бер тапкыр гына даруханәгә керүен әйткән. Хатын-кызлар даруханәләргә ешрак йөри, ди белгечләр.

Әзер булырга кирәк

«Хәлләрнең теге яки бу якка үзгәрүенә әзер булып тору мөһим. Яңа ел бәйрәмнәреннән соң күпләр сәфәрләрдән, шул исәптән чит илләрдән кайта. Моны исәпкә алу кирәк». Россия Хөкүмәте Рәисе Михаил Мишустин Хөкүмәт каршындагы Коронавирус инфекциясе таралуга көрәш буенча координация советы президиумы утырышында шулай дип белдерде. Видеоэлемтә режимында үткәрелгән утырышта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты.

Михаил Мишустин билгеләп үткәнчә, дөньяда коронавируска бәйле хәлләр, яңа штамм таралу аркасында, күзгә күренеп начарая. Премьер-министр сүзләренә караганда, инфекциягә каршы көрәш чаралары элеккечә үк кала. Вакытында тест уздыру бик зур әһәмияткә ия. Чирне ничек тә алданрак ачыклау сырхауны тизрәк дәвалый башлау һәм башкаларны чир йоктырудан саклау мөмкинлеге бирә.

Премьер-министр фикеренчә, вакцинация, элеккечә үк, инфекция таралуга каршы көрәшү буенча иң ышанычлы ысул булып кала. «Россиянең һәр төбәгендә яшәүчеләрнең бушлай прививка ясатуы, вакыты җитсә – кабат ясатуы өчен, барлык мөмкинлекләр тудырылган. Моны Россия Президенты игътибар белән күзәтеп бара», – диде ул.

Михаил Мишустин узган елның 1 июленнән ковид кичерүчеләргә җентекле диспансеризация уздыру программасы башлануын искә төшереп үтте. Быел бу максатка 8 миллиард сум күздә тотылган.

Ахыры 2 нче биттә >

Меңнән артык кеше эшли

Татарстанда «Мәскәү – Казан» М12 түләүле автомобиль юлын төзүдә тәүлек әйләнәсе меңнән артыграк кеше эшли. Бу хакта «Автодор» дәүләт компаниясенең матбугат хезмәте хәбәр итә. «Татарстанда юлның сигезенче этабы төзелә: ясалма корылмалар булдыру, Идел һәм Мишә елгалары аша вакытлыча күпер салу, бу елгаларда һәм Зөядә төп күперләрнең терәкләрен кору эшләре алып барыла. 10 гыйнвардан әлеге эшләргә 1020 кеше җәлеп ителде», – диелә хәбәрдә. Кышкы чорда тирән уентыларда һәм биек өемнәрдә юл төзү эшләре алып барыла. Әлегә анда төзелеш техникасы гына йөри ала. Автомобильчеләргә ике елдан соң М12 юлыннан файдалану мөмкинлеге ачылачак.

Исегезгә төшерәбез: М12 Европа – Көнбатыш Кытай халыкара автомобиль юлының бер өлеше булып тора. Татарстанда ул Кайбыч, Апас, Кама Тамагы, Югары Ослан, Лаеш һәм Яшел Үзән районнары аша уза.

Сабыйларга акча арта

Татарстанда бала туганда бер тапкыр бирелә торган акча күләме арта. Биредә моңа кадәр социаль яклау органнары биреп килгән пособие турында сүз бара. Бу хакта республиканың Пенсия фонды бүлеге хәбәр итә.

Түләү күләме хәзер 18886 сум 32 тиен тәшкил итә. Ул баланың эшләмәүче әтисе яки әнисенә, опекуны, уллыкка (кызлыкка) алучыга яки баланы гаиләсенә сыендыручыга бирелә. Берьюлы 2 яки аннан күбрәк игезәк туган очракта, пособие һәр сабыйга түләнә. Шул ук вакытта бу акча баланың әтисе дә, әнисе дә (яки аларны алыштыручылар) эшләмәгәндә генә бирелә. Пособие алу өчен бала туганнан соң алты айдан да соңга калмыйча яшәү урыны буенча Пенсия фондының клиентларга хезмәт күрсәтү бүлегенә гариза белән мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Яңалык

Тизлек төрмәгә илтә

Яңа елның беренче ае машина йөртүчеләр өчен яңалык алып килде. Юлда тәртипсез кыланучыларга, тизлек арттырып йөрүчеләргә кагыла ул. Зур күләмдә штраф, хөкем ителү һәм төрмә – юлдагы җаваплылык бәһасе каттыйрак булачак.

Нәрсәдән башланды?

Закон чыгаручыларның тизлек яратучылар белән көрәш башлау турында сүзләре 2021 елның ноябрендә Мәскәүдә булган бер авариядән соң ешрак ишетелә. Мәгълүм булганча, узган ел автоблогер Сәед Губденский Кутузов проспектында куркыныч юл һәлакәте китереп чыгарды: BMW машинасында ул каршы як полосага чыкты. Машина йөртүче дә, аның пассажиры да исән калмады. Сәеднең моңа кадәр дә юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуда тотылганы булган иде. Аны «права»сыннан да мәхрүм итеп карадылар. Аңлашылганча, штрафлар да, машина йөртү хокукыннан колак кагулар да әллә ни куркытмаган…

Хәтерләсәгез, апрель аенда тагын бер блогерның юлда тупас кылануы чак кына үлем белән тәмамланмый калган иде. Эдвард Билл, үз машинасында каршы як полосага чыгып, башка машина белән бәрелеште. Моның аркасында бер хатын-кызга җитди зыян килгән.

Россия Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин декабрь аенда ук автомобильчеләргә бәйле законны катгыйландыру кирәклеге турында үзенең «Телеграм»дагы сәхифәсендә әйткән иде. «Юлда тәртипсез йөрүчеләр аркасында үлгән, инвалид калган кешеләр хакында гел ишетеп торабыз. Гади штрафлар гына куркытмый аларны. «Хайп» өчен алар кагыйдә бозуга кадәр барып җитә, әйләнә-тирәдәгеләрнең сәламәтлеге һәм тормышы турында уйланмый. Законны катгыйландыру кирәкле эш иде», – дип уртаклашты ул.

Нинди үзгәреш?

Машинада барганда тизлекне арттырган, каршы як полосага чыккан һәм аның өчен моңа кадәр дә берничә тапкыр административ җаваплылыкка тартылган йөртүчеләрне җинаять җаваплылыгына ук тартачаклар. Каршы як полосага, каршы трамвай юлларына берничә тапкыр чыккан яки тизлекне сәгатенә 60 чакрымнан күбрәккә арттырган өчен ике елга төрмәгә утыртырга мөмкиннәр. Моннан тыш, 200 меңнән алып 300 мең сумга кадәр яки 1–2 еллык хезмәт хакы күләмендә штраф та каралган. Кагыйдә бозу очрагы янә кабатланса, җәзасы тагын да кырысрак булачак: хөкем ителү вакыты – 3 елга, штрафы ярты миллион сумга җитәргә мөмкин.

Статистикага күз салсаң, машина йөртүчеләрнең 40 проценттан артыгын тизлекне арттырган өчен административ җаваплылыкка тарту гына куркытмый. Андыйлар яңадан кагыйдәләрне тупас рәвештә боза.

Россия Эчке эшләр министрлыгының Мәскәү буенча Эчке эшләр идарәсе Иҗтимагый советы әгъзасы Петр Шкуматов белдергәнчә, бу закон күптән кирәк иде инде.

– Әгәр кеше юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен берничә тапкыр эләксә, (бу очракта сүз – тизлекне сәгатенә 60 чакрымнан арттыру һәм каршы як полосага чыгу турында) аны җәмгыятьтән аерырга кирәк. Яңа закон машина йөртүчеләрнең аз өлешенә генә кагылачак, әмма явызларча хокук бозучылар үзләрен юлларда мөмкин булганча сак тотарга мәҗбүр булачак, – дигән фикердә ул.

Шунысын да әйтергә кирәк: 2022 ел башыннан Россиядә юл-транспорт һәлакәтләре 2 меңгә җиткән. Аварияләрдә 230 кешенең гомере өзелгән, 700 кешене коткарып калганнар.

Сүзгә-сүз

Вячеслав ВОЛОДИН, Россия Дәүләт Думасы Рәисе:

Бүген күп кенә даруханәләрдә бер үк дарулар төрле бәядән сатыла һәм аерма шактый зур. Уйлавымча, әлеге тармакны тулысынча дәүләт кулына бирергә, ягъни дару җитештерүче ниндидер шикле шәхси компанияләрнең лицензиясен тартып алып, җитештерү хокукын тулысынча дәүләт предприятиеләренә тапшырырга кирәк.

(Вячеслав Володинның Telegram-каналыннан)

ТАТАРСТАНДА – МАШИНА БАЗАРЫ

2020 ел белән чагыштырганда былтыр Татарстанда кулланылышта булган автомобильләр сату күләме 0,8 процентка арткан. «Авито – Авто» мәгълүматларына караганда, мондый машиналарның уртача бәясе 24,2 процентка артып, 385000 сумны тәшкил иткән.

УЗГАН ЕЛ ИҢ КҮП САТЫЛГАН МАШИНА МАРКАЛАРЫ

Марка	Өлеше	Уртача бәясе, сум
ВАЗ (LADA)	32,0%	160000
Kia	7,7%	718000
Hyundai	5,9%	650000
Chevrolet	4,8%	330000
Renault	4,6%	560000

«КАМАЗ-Мастер» лидерлыкны бирми

Согуд Гарәбстанында узучы «Дакар» ярышының тугызынчы этабында Эдуард Николаев экипажы йөк автомобильләре арасында финишка беренче булып килде. Чаллының «КАМАЗ-Мастер» командасы егетләре 287 чакрым махсус участокны 2 сәгать 38 минут 43 секундта узды. Икенче урынны да безнең егетләр – Дмитрий Сотников экипажы алды. Чех Мартин Мацик өченче булды.

Йөк машиналары арасында гомуми зачетта Дмитрий Сотников экипажы алда бара. Икенче урындагы Эдуард Николаев егетләре иптәшләреннән 8 минут 51 секундка калыша. Антон Шибалов экипажы – өченче урында. «КАМАЗ-Мастер»ның Андрей Каргинов җитәкчелегендәге дүртенче экипажы – тугыз этаптан соң бишенче урында.

1 гыйнварда ярышка чыккан автоузышчылар 14 гыйнвар көнне Җиддә каласында финишка килеп җитәр дип көтелә.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

БИТКОИН ТҮНТӘРЕЛЕШЕ

Дөнья икътисады һәм сәясәте турбулентлык зонасында үрле-кырлы сикерүен дәвам итә. Ел башы акчасын криптовалютага тыгучылар өчен күңелсез яңалыклар белән башланып китте: цифрлы валюталар кискен түбән тәгәрәде. Артык акчасын кая куярга белмичә биткоин алган спекулянтлар бүген зур югалтулар кичерә.

Иң башта криптодержава дип саналган Казахстандагы фетнә виртуаль акчаның тез астына сукты. Дала илендәге майнинг фермалары, интернет өзелеп, эштән туктады һәм криптобиржаларда биткоиннар, альткоиннар чәчелде. Аннан соң мәйданга цифрлы акчаларны селкетә торган башка сылтаулар чыкты. Криптовалюта җитештерү гаҗәп кызык процесс бит инде ул: гаять зур энергия файдаланып, виртуаль дөньяда цифрлар язына, шуларны кешеләр акча дип таный. Икътисад өчен бөлдерүдән башка берни дә бирми бу, чөнки берничә дә матди кыйммәтләр җитештерелми. Спекулянтлар ота я оттыра инде. Хәзерге вакытта алар зур суммаларны оттыралар. Тагын берникадәр вакыттан соң оттыру кочәергә мөмкин, отышка да әверелә ала. Уен автоматына акча салган кебегрәк инде.

Соңгы тәүлекләрдәге биткоин түнтәрелешен эре инвесторларның (спекулянтларның дип укыйк) криптовалюталардан качуы китереп чыгарды. Спекулянтларның тәртәне кирегә боруының сәбәбе исә АКШ ФРСның акча басуны киметергә һәм март аенда бөтенләй туктатырга ниятләвен игълан итүдә иде. Янкилар март аенда берьюлы процент ставкаларын да күтәрергә җыена. Менә шушы яңалык спекулянтларны доллар сатып алырга этәрә дә инде, чөнки Америка кәгазе кыйммәтләнәчәк. Фонд биржаларында кыйммәтле кәгазьләрнең дә түбәнгә таба мәтәлчек атуы башланырга мөмкин. Үзегезне спекулянт итеп тоегыз, әйдә. Сезнең кулыгызда озакламый бәясе төшәчәк акцияләр, криптовалюталар һәм башка чүп-чар бар. Ә доллар дип аталган кәгазьнең бәясе күтәреләчәк. Сез, башыгызга тай типмәгән булса, бәясе төшәчәк уенчыкларыгызны сатып, кыйммәтләнәчәк кәгазьләр алып калырга тырышачаксыз. Криптобиржаларда менә шул сәбәпле цифрлы акчаларны долларга әйләндерү башланды да инде. Иртәгә башка бер сигнал килеп, долларлар очсызланачак дигән сүз таралса, биткоиннар яңадан кыйммәтләнә башлаячак. Менә шундый уен инде ул.

Дүшәмбе сәүдәсендә биткоин 40 мең долларга кадәр түбәнәйде. Аның бәясе өк күптән түгел генә 60 мең тирәсендә йөри иде. Башка цифрлы валюталар да мәтәлчек атты. Ел башыннан (ун көн эчендә) биткоин 14 процентка очсызланып, спекулянтлар 102 миллиард доллар югалтты. Барлык криптовалюталарның очсызлануы 1 гыйнвар белән чагыштырганда 312 миллиард долларга җитте. Ә үлчәүне ноябрь аеннан салсак, 1,072 триллион долларлык куык, тишелеп, җилгә очты. Финанс белгечләре ел ахырына биткоинның 20 мең долларга гына калу ихтималын да әйтә. ФРС финанс системасыннан долларларны ниндi тизлектә җыеп алуга бәйләнгән бу. Биржа куыклары да шиңә башласа, янки банкирларының, куркып, янә акча басарга керешүе ихтимал. Ул чакта яңадан криптокуыклар кабарачак. 2022 ел финанс ягыннан зур тетрәнүләр белән тарихка керепкалыр, мөгаен. Сум-доллар бизмәненең кай якка авышасы исә Россиянең Үзәк банкы нинди карарлар кабул итүгә дә бәйле булачак.

Россиядә

АШЛЫК ҖИТӘРМЕ, БЕТӘРМЕ?

Дөньякүләм бара торган сәяси киеренкелек һәм икътисади хәвефләр сикәлтәсендә Россия дә тирбәлә. Женевадагы АКШ – Россия сөйләшүләре нәтиҗәсез диярлек тәмамланды. Дөрес, безнең сәясәтчеләр: «Россия соңгы утыз елда беренче тапкыр Америка белән бер дәрәҗәдә сөйләшүләр өстәле янына утырды», – дип шатланды шатлануын. Әммә Вашингтон куркынычсызлык буенча Россия куйган таләпләрнең берсен дә үтәмәде, Мәскәү дә Украина чигеннән гаскәрләрен алмаячак. Дөрес, киләчәктә якын арага һәм уртача ераклыкка оча торган ракеталар буенча ниндидер килешүгә булу ихтимал, әмма анысы да әлегә, кем әйтмешли, суга сәнәк белән генә язылган. Көнбатыш чиктә киеренкелек үз урынында кала, беркая да китми.

Гомумән, планетада зур шом яши, зур сәясәтчеләр авыр сынаулар булачагын белә һәм шуңарга әзерләнә. Бу ашлык базарындагы зур киеренкелек туудa да ачык күренә. Азык-төлек бәяләре исә күтәрелә һәм күтәреләчәк. Бердән, үткән ел Җир шары масштабында корылык булды. Икенчедән, кәгазь акчаны чамасыз күп басыла, өченчедән… Өченчедән, Кытай бөтен дөньяда җитештерелгән ашлыкның яртысыннан күбрәген сатып алып, запаска салып куйды. Планета халкының 20 проценты гына яшәгән ил кукурузның 69 процентын, дөгенең 60 процентын, бодайның 51 процентын үз амбарларына тутырды. Чиннарның стратегиясен аңлап була: алар бит кәгазьне чын матди кыйммәтләргә алыштыра. Корылык кабатланса һәм ачлык көчәйсә, алар алтыннан купка кыйммәтләрәк стратегик запасларга ия булачак. Сугыш башлана калса да кемнәр отасы билгеле инде монда. Ашарына булмаса, озак кылыч селти алмыйсың.

Россия исә соңгы елларда бодай экспортын бик нык арттырды. Валютага кытлык булмаса да, чит илләргә бик күп ашлык агылды. Капиталы да яңадан оффшорларга кача бит әле аның. Алдагы елларда мул лык шартларында бу ярый иде әле. Үткән ел исә, корылык, сезонлы эшләр вакытында эшче кулларның җитмәвенә сәбәпле, уныш купкә түбән булды. Җыеп алдык дип игълан итепгән санларның да өстән язулар нәтиҗәсе икәне мәгълүм. Бу сер түгел. 2021 елда 120,7 миллион тонна ашлык җыелды, бу 2020 елдагыдан 9,6 процентка кимрәк, ди Росстат. Бодай уңышы 12 процентка кимрәк, бу – 10 миллион тонна уңышны дигән сүз. Арпа 14 процентка кимегән, минус 14,6 миллион тонна игеннары.

Бер бездә генә түгел, ашлык экспортлаучы АКШ, Канада, Бразилиядә дә уңыш соңгы 19 елда иң түбәнге булган.

Россиянең иң тырыш һәм ашлыклы күп игүче төбәкләре – Татарстан, Башкортстан, Оренбург өлкәләре уңышны алдагы еллардан күпкә кимрәк җыйды.

Азык-төлеккә бәяләрне югарыга этүче төп факторга әйләнә бу киму. Ашлык бәясе иткә һәм сөткә, йомыркага да бәяләргә өске куа бит. 2021 ел азык-төлек инфляциясенең соңгы ун елдагы иң югары күрсәткечен бирде. Бу юллар язылганда, урамда талгын гына кар ява. Кар түгел, икмәк ява, дип кабул итик моны, чөнки кар күп булды, кыш та карсыз килеп, яз да дым аз булса, хәл бик нык авыраячак.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

ӘЗЕР БУЛЫРГА КИРӘК

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Утырышта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов республикада коронавирус инфекциясенә бәйле вәзгыять турында сөйләде. Ул, аерым алганда, ковид таралуга карата үзенең төп чараларына, вакцинациянең барышы, сәламәтлек саклау өлкәсе эшчәнлеге һәм эшмәкәрләргә ярдәм итүгә тукталды. Аның әйтүенчә, республика бюджетыннан коронавируска каршы көрәшкә, шул исәптән медицина оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлеге өчен шартлар тудыруга, аларны махсус кием-салым һәм индивидуаль саклык чаралары белән тәэмин итүгә, дарулар сатып алуга өстәмә рәвештә 3,5 миллиард сум акча бүлеп бирелгән.

Татарстан Президенты әйтүенчә, 11 гыйнварга республикада чир йоктырган 43 мең 749 кеше теркәлгән. Пандемия чорында барлыгы 36 мең 800 кеше савыккан. Кызганыч, 1497 кеше вафат булган. Татарстанда чир күрсәткече 100 мең кешегә 1123 кеше тәшкил итә.

Республикада ковидка каршы халыкны вакцинациялэү дәвам итә. 2 миллион 298 мең кеше – прививканың беренче уколын, 1 миллион 863 мең 587 кеше икесен дә кадаткан. 140 мең кеше кабат вакцинация ясаткан. Республикада барлыгы 170 вакцинация пункты эшләп килә. Шулай ук кешеләргә өйләренә килеп прививка ясау да оештырылган.

Татарстан Президенты искәртеп үткәнчә, республика коронавирусның яңа – «омикрон» штаммы үтеп керү ихтималына тулысынча әзер. Әлегә мондый очраклар теркәлмәгән. Обсерваторлар, йогышлы авырулар хастаханәләрендә махсус бокслар әзер. Өстәмә ятак урыннар булдыру мөмкинлеге бар. Моннан тыш «Казан» һәм «Вигеш» халыкара аэропортларында «омикрон» штаммы таралган илләрдән кайткан кешеләргә тестлар уздырыла.

Узган елның 1 июленнән республикада, эпидемиологик вазгыятькә карап, тест үткәрү куләме арттырылган. Коронавирус инфекциясен ачыклау өчен 24 лаборатория эшкә җигелгән. Шулай ук дәүләт һәм хосусый медицина оешмаларында экспресс-тестлар уздырыла. 100 мең кешегә 306 ПЦР-тест туры килә.

Шул ук вакытта Президент республикада коронавируска бәйле хәлләрнең тотрыклы булып калуын билгеләп үткән. Урын-ятаклар, дарулар җитәрлек. Җәмәгать транспортында QR-кодлар системасы эшләп килә. Барлык җәмәгать урыннары Роспотребнадзор билгеләгән таләпләр нигезендә эшли.

БЕРЕНЧЕ НӘТИҖӘЛӘР

Яңа елга зур өмет һәм ниятләр белән кергән идек, аның беренче ун көне ничек узды? Быел Хөкүмәт йортында уздырылган беренче утырыш нәкъ менә шуларга багышланды.

Кунаклар һәм кунак итүчеләр

Бәйрәм көннәрендә Татарстан барлыгы 140 мең турист кабул иткән. Араларында күрше төбәкләрдән килүчеләр дә, ерак араларны якын итүчеләр дә бар. Әйтик, 31 декабрьдән 9 гыйнварга кадәр Габдулла Тукай исемендәге «Казан» халыкара аэропортында гына да барлыгы 105 меңнән артык пассажирга хезмәт күрсәтелгән. Узган елның күрсәткечләре белән чагыштырганда, 47,4 процентка артыграк.

Бу – кунакка килүче һәм кунакка китүчеләрнең гомуми саны. Татарстанның Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Айгөл Балахонцева сүзләренчә, татарстанлылар арасында да бәйрәм көннәрен читтә уздыручылар шактый булган. «Чит илдән кунаклар кабул итмәсәк тә, татарстанлылар үзләре читкә кунакка барудан куркып тормады. Иң популяр илләр рәтендә – Мисыр, Төркия һәм Берләшкән Гәрәп Әмирлекләре», – диде ул. Әлегә 3 илгә баручылар 20 меңгә якын булган.

Янә Татарстанга кайтсак, кунаклар өчен бәйрәм көннәрендә республикада барлыгы 308 кунакханә, хостел, шифаханә һәм ял базалары эшләгән. Казан шәһәре һәм Татарстан кунакханәләре ассоциациясе мәгълүматларыннан күренгәнчә, 31 декабрьдән 2 гыйнварга кадәр кунакханәләрнең 79 проценты, ә 2 гыйнвардан 9ына кадәр 90 проценты тулы булган.

Татарстанның вице-премьеры Ләйлә Фазлыева исә Татарстанда кунак булган туристларның иң яраткан урыннарын атады:

– Казан Кремле, Зөя утрау-шәһәрчеге, Алабуга шәһәре, Бөек Болгар һәм Чистайны туристлар аеруча үз итте. Шулай ук бу исемлеккә Татарстан халкы һәм кунаклары ел да яратып бара торган Арча районындагы Яңа Кырлай авылында урнашкан Кыш бабай резиденциясен дә кертми кала алмыйм. 30 декабрьдән 9 гыйнварга кадәр әлеге резиденция барлыгы 3000 кунак кабул итте, – диде ул.

Әйлән-бәйлән генә түгел

Бәйрәм елга бер килгәч, аны шәп итеп каршы алырга һәм озатып җибәрергә кирәк. Шушы сүзләрне истә тотып, 1 гыйнвардан 9 гыйнварга кадәр Татарстанда барлыгы 1,5 меңгә якын мәдәни чара уздырылган, һәм аларда 340 мең кеше катнашкан. Бәйрәмнән соңгы ялларда иң күп чаралар Татарстандагы музей-тыюлыкларга туры килә икән. Барлыгы 222 меңгә якын тамашачы беләнн 986 чара узган аларда.

Мәдәният министрының беренче урынбасары Юлия Әдһәмова сүзләренчә, мәдәни күңел ачу чаралары әле дәвам итә. «Без инде Кукмарада – «ITEKFEST», Яшел Үзәндә «Свет Вифлеемской звезды» фестивальләрен уздырырга өлгердек. Алда сезне тагын да кызыклы чаралар көтә. Иң мөһиме – саламәт булыйк», – диде ул.

Бала күңеленең тауда чагы

Ләйлә Фазлыева балалар ялының ничек узуы турында да сөйләде. Елдагыча, хәвефсез булмаган. Әйтик, каникулда 35 бала, тюбта шуып, җәрәхәт алган, балалар арасында өшүнең дә өч очрагы теркәлгән.

– Балалар өчен актив ял бик әһәмиятле, ләкин күңел ачу хәвефсез узсын иде. Балаларны ялгыз калдырмаска тырышыгыз. Тюб белән тау шуганда, бигрәк тә. Бу турыда инде бик күп сөйләнде, зыян күрүчеләр дә ел саен булып тора. Кыш шунысы белән куркыныч инде, – диде Фазлыева.

Таләпләр үтәлгәнме?

Бәйрәм чараларының республикадагы коронавирусны вазгыятькә бәйле рәвештә билгеләнгән шартларны исәпкә алып уздырылачагы алдан әйтелгән иде инде. Авырулар санына бәйле нәтиҗәләрне ясарга иртәрәк булса да, шушы таләпләрнең ни дәрәҗәдә үтәлүе инде билгеле.

– Бәйрәмнәр чорында Татарстанда 400дән артык тикшерү уздырылды. Оешмаларның якынча 10 проценты без билгеләгән шартларга битараф булып чыкты. Ләкин, гомумән алганда, оператив штаб әйткәннәрне үтәделәр, – диде Ләйлә Фазлыева.

Татарстан вице-премьеры алга таба да саклануга киңәш итте. «Авыручылар саны кими башлау белән, битлекләр салына, чикләүләр дә онытыла. Шактый урыннарны үзем барып күрдем, QR-кодларны да кем тикшерә, кем – юк. Әлегә тагын генә чикләүләр йомшарачак, дип әйтә алмыйбыз. Аларның язмышы киләсе атнадагы вазгыятькә бәйле. Көтик», – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

РОССИЯ МАТБУГАТЫ КӨНЕ БЕЛӘН

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИНның Россия матбугаты көне белән КОТЛАВЫ

Хөрмәтле массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәткәрләре! Журналистлар һәм редакторлар, нәширләр һәм полиграфистлар, ветераннар һәм яшь каләм тибрәтүчеләр! Сезне ихлас күңелдән Россия матбугаты көне белән котлыйм!

Бу бәйрәм үзенең тырыш эшчәнлеге белән мәгълүмат дөньясын булдыручы, гражданнарның иң төп конституциячел хокукларының берсе булган сүз ирегең үтәүне тәэмин итүче барлык хезмәткәрләрне дә берләштерә. Төрле тематик юнәлештәге басмаларның сәхифәләрендә купмиллә тле илебез тарихы, үткән чорлар һәм бүгенге көннең рухы чагылдырыла. Мәгълүмат кырының үргылып үзгәрүенә, массакүләм мәгълүмат чараларының яңа үсеш юлларын эзләвенә карамастан, басма сүз элеккечә абруйлы һәм кирәк булып кала.

Бүген сезнең һәрберегез – нинидер дәрәҗәдә аналитик һәм мәгълүматчы, колумнист һәм күзәтүче, публицист һәм блогер да. Сез укучыларыгызны арттыру өчен заманча басма мөмкинлекләреннән һәм иң яңа цифрлы технологияләрдән оста файдаланасыз, көн сулышын тоярга, вакыйгаларның үзәгендә булырга омтыласыз. Купканаллы һәм интерактив форматлар, күз явын алырлык полиграфия, мәгълүматны һәрьяклап үлчәнгән итеп биргәндә «кайнар» темаларның гадәти булмаган ракурсларын эзләү сезгә даими укучыларыгызны саклап калырга һәм яңаларын табарга ярдәм итә. Беркемгә дә сер түгел, иң мөһим проблемалар һәм әһәмиятле сәяси карарлар, игътибар иткәнче, репортаж, интервью, мәкаләләр булып басылып чыкканчы, җәмгыять карашыннан читтә калып килә. Сез кабул ителгән башлангычларны һәрвакыт аңлатып бирәсез, алда торган мәсьәләләрне тизрәк хәл итәргә булышасыз, халык фикерен һәм кәефен җиткерәсез. Шуңа күрә сездән акыл һәм йөрәк аша үткәреп язылган тирән эчтәлекле мәкаләләр, яңа креатив проектлар көтәбез.

Кадерле дуслар! Бәйрәм көнегездә сезгә нәтиҗәле хезмәттәшлек, һөнәри осталык, эшкә һәм ил журналистикасының иң яхшы традицияләренә тугрылык өчен рәхмәт сүзләре җиткерергә рөхсәт итегез. Сезгә республикада, илдә һәм дөньядагы хәлләрне күзәтеп бару өчен – үткен караш, төрле фикерләрдәге хакыйкатьне аңлау һәм кабул итү өчен – сизгерлек, күргәнне һәм ишеткәнне дөрес язу өчен очлы каләм телим.

Эшегез һәрвакыт шатлык һәм канәгатьләнү хисе китерсен. Сәламәтлегегез нык булсын, алда сезне озын, зур вакыйгаларга бай тормыш көтә. Сезгә илһам чишмәгезнең саекмавын, яңа иҗади уңышлар, бәхет, игелек һәм иминлек телим! Бәйрәм белән!

АВЫР, ӘММА КҮРКӘМ ХЕЗМӘТ ИЯСЕ СЕЗ

12 гыйнвар – Россия прокуратурасы хезмәткәрләре көне. Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин һөнәри бәйрәмнәре уңаеннан республика прокуратурасы органнары хезмәткәрләрен һәм ветераннарын котлады.

«Төп-төгәл 300 ел элек – Петр I идарә иткән дәвердә Россиядә прокуратура институты барлыкка килә, – диелә котлауда. – Прокуратура органнары иң катлаулы борычлар чорларында дәүләттә аерым бер әһәмиятле урын алып тора, ә прокурорлар һәрвакыт закон сагында була.

Бүген прокуратура – илебездә хокук саклау системасының төп институтларыннан берсе. Кешеләрнең хокукларын һәм ирекләрен саклау-яклау, җинаятьчелекнең барлык төрләренә каршы көрәшү прокуратураның төп бурычлары булып тора.

Республика җитәкчелеге авыр, әмма бик күркәле, күркәм хезмәтегез, законлылык һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүегез өчен эчкерсез рәхмәтләрен белдерә. Сезгә һәм якыннарыгызга нык сәламәтлек, иминлек, закон сагында иң катлаулы бурычларны хәл кылуда уңышлар, бетмәс-төкәнмәс көч-куәт телим!»

БИШ ЕЛ ЭЛЕК ХЫЯЛ ИДЕ...

2016 елның җәендә Балтач районында үткән терлекчеләр бәйрәмендә республиканың ул чактагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов район җитәкчеләре һәм терлекчеләрнең күңеленә көнчелек оеткысы салып киткән иде.

Кукмараның көненә 200 тонна сөт сава башлаган көннәре иде ул. «Дөресен әйтим, без, республика җитәкчеләре, бу чикне иң беренче булып сез үтәрсез дип уйлаган идек. Әнә кукмаралылар шыпырт кына артыгыздан килделәр дә сезне узып киттеләр. Нигә әле сезгә дә шундый сикереш турында уйланмаска? Алдыгызга шундый конкрет зур бурычлар, әйтик, елга йөз мең тонна сөт саву бурычын куймаска?! Моңа сезнең бөтен мөмкинлекләрегез дә бар», – диде Марат Әхмәтов. Ул чакта бу бүй җитмәслек хыял кебек иде, чөнки планка бик югары күтәрелгән, бик зур сан иде. Моны, билгеле, министр үзе дә аңлады. Тикмәгә генә, бу саннарны әйткәч, район башлыгына борылып карап: «Район башлыгы егылмады, димәк, өметләнергә була», – димәгәндер.

Ниһаять, биш елдан соң әлеге югары план үтәлгән: 2021 елны район терлекчеләре 104 мең 100 тоннадан артык сөт савып тәмамлаган. Әле бу санга шәхси хуҗалыклардан җыйналган 35 мең тонна сөтне кушарга кирәк. Җәен район тарихында беренче тапкыр көндәлек 300 тонна сөт сава башлаган балтачлылар бер елга икенче рекордны чикне үтте.

– Район өчен моңарчы күрелмәгән саннар, тарихи вакыйга булырлык яңалык болар. Нигезе кимендә утыз еллап элек салынса да, төп этәргеч, дөрестән дә, Марат Готовичның наказы булды кебек, – ди район башлыгы Рамил Нотфуллин. – Соңгы дүрт-биш елда без сөт җитештерүне һәр елны 7–8, 10 процентка үстерә-үстерә, шушы нәтиҗәгә ирештек. Безнең район күп еллар республикада сөт җитештерү буенча лидер булды. Мәсәлән, 2013 елда без елына 56 мең тонна сөт җитештергәнбез, ул елда да иң алдынгыларның берсе идек…

Санаулы ел эчендә җитештерүне икеләтә арттыру өчен, билгеле, бик күп төрле шартларны үтәргә туры килә. Нәсел эше, азык технологияләре, заманча корылмалар... Районда бүген 6 хуҗалыкта саву заллары булган заманча фермалар эшли, ике хуҗалык роботлар куйган, ун хуҗалыкта көтүне идарә итү системасы, 12 хуҗалыкта ашатуны идарә итү программасы кертелгән. Бүген 4500 савым сыеры заманча комплексларда асрасла, тагын ике хуҗалыкта 1200 баш терлеккә шундый корылмалар төзү эше бара. Тукымлы орлыклар белән эшләү өстенә, Дания, Бельгия, Чехия, Кировтан нәселле терлекләр сатып алынган. Азык үзәкләре, азык цехлары булдырылган, хәзерге көндә миксерсыз хуҗалыклар юк, диләр.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Район хуҗалыкларында тәүлегенә 60–70 килограммга кадәр сөт бирүче рекордчы сыерлар бар. Хәтерлим әле, бер елны районда алдынгы сыер савучы: «Их, бөтен сыерлар да 24әр килограмм сөт бирсә», – дигән иде. Хәзер инде 30–40 килограмм сөт бирүче сыерларга берәү дә шаккатмый. Тик шушындый сыерларны үстерү-асрау гына җиңел түгел. Элекке кебек башак-печән ашатып кына аллә кая сикереп булмый…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ТАШЛЫК ЕГЕТЕ

Яңа ел яллары бик озакка сузылып, шактый ук ялыктыра башлагач, дусишләргә шалтыратырга тотындым. Янәсе, алар да бик азапланмыймы? Алмаз Хәмзин онытгы белән мәш килә, балалар өчен берәр әкият язарга да хыялланып йөри икән. Ә минем бер сүз дә сырлаган юк, кая анда әкият язу!

Яшь барган саен, аралашу даирәсе тарайганын беләм, әмма бу «авырлык»ны үз җилкәмдә татыган юк иде. Бу хакта Алмазга да әйттем. Ә ул: «Әйдә, очрашыйк соң!» – диде. Бәхеткә, уртак дустыбыз, Дәүсоветның матбугат үзәгендә эшләүче Җәүдәт Юнысовның кизү тору көне икән, шунда очрашырга сүз куештык. Өч дусның бергә күрешеп күңел бушатуы, «пар чыгаруы» – бер хәл, әле тагын бер дустыбыз Разил Вәлиевнең туган көне дә җиткән иде. Алмазга: «Бигрәк җайсыз көнне туган инде синең авылдаш», – дим.

– Нигә алай дисең?

– Бәйрәм арасы, ыгы-зыгы вакыт, җитмәсә, гәҗит тә чыкмый, гәҗит аша котласак, тагын да шәп булыр иде.

– Борчылма, Риман дус, юбилей ел буе дәвам итә ул.

Алмаз мине шулай дип тынычландырды үзе, әмма бөтен сөйләгән сүзебез Разил Вәлиевкә барып тоташа иде. Хикмәт Разил белән Алмазның бер авылдан булуында, бер парта арасына утырып укуларында гына да түгел. Разил – бөтен татар дөньясында иң билгеле шәхесләрнең берсе. Һәм алар, Алмаз әйтмешли, инде 75 ел бергә. Монысын бераз арттырды инде Алмаз, алар бер елгы булсалар да, туганда ук бер-берен белеп тумаган бит. Моны Алмазга да әйттем. Ә ул көлә генә. «Безнең туу ике гаиләнең дә планына кертелгән булган бит», – ди. Имеш, 4 гыйнвар көнне Разил тугач, Алмазның әтисе Наил абый: «Разилгә иптәш кирәк булачак», – дип әйткән дә, нәкъ 9 айдан Алмаз туган, ди. Әлбәттә, нәкъ тугыз айдан түгел инде, ике атнага соңарып, 18 сентябрьдә туган Алмаз, әмма күзен ачкач та: «Разилнең хәлләре ничек?» – дип сораган, имеш.

Милли хисләр

Шулай уйнап-көлеп, бераз шыттырыбрак сөйләшсәк тә, аларның бүгенгә хәтле бер-берен югалтмыйча яшәве шактый уйландыра. Бит Алмаз үзе әйтмешли, тормышын иҗатка багышлаган кешеләр арасында көнләшү хисләре тумыйча кала алмый, сабакташлар арасында бигрәк тә. Әмма Ташлык егетләрендә үз халкыңа хезмәт итү хисләре бик иртә бөреләнеп, башка хисләргә урын калдырмаган дип уйлыйм. Алмаз бер гыйбрәт сөйләде әле. Сабакташлар башлангыч белемне үз авылларында ала. Аннан соң Шәңгәлче мәктәбенә йөри башлыйлар. 8 нче сыйныфтан соң Түбән Каманың эшчеләр бистәсендәге мәктәбенә китәләр. Ә анда төгәл фәннәр урысча укытыла. Татар мәктәбендә «дүрт»кә-«биш»кә укыган егетләрнең көндәлегендә «икеле», «өчле» билгеләре күренә башлый. Төп сәбәп – урысча белмәү. Шуның өстенә кайбер укытучылар аларга кимсетеп карый. Янәсе, татар – второсортный халык. Егетләрнең җен ачулары чыга. Хәтта беркөнне аеруча җаннарына тигән бер укытучының тәрәзәсенә вак таш та ыргытмакчы булалар, ярый әле тыелып калалар. Монысы, әлбәттә, бер дә ярый торган эш түгел. Шуннан соң Разил: «Алмаз, бу мәктәптә безгә рәт булмаячак, әйдә Бикләнгә китик!» – ди. Биклән авылы мәктәбе иң абруйлылардан санала. Беркемгә берни әйтеп тормыйлар болар. Ни хикмәт, мәктәп җитәкчелеге Разил белән Алмазны берсүзсез кабул итә. Класс бүлмәсенә өстәмә ике парта да кертеп куялар.

Әмма берничә көн узуга, Бикләнгә бистә мәктәбе укытучылары килеп, егетләрне кире үзләренә алып кайтып китәләр. Бернинди каты сүз әйтү юк. Киресенчә, иң ягымлы укытучыларга әйләнгәннәр. «Димәк, милли сәясәттә хата җибәрүләрен аңлаганнар», – ди Алмаз. Әлеге вакыйга егетләрнең күңеленә бик тирән уелып кала. Зур сәясәткә кереп китүнең башы булгандыр ул, мөгаен.

Мин үзем Разил Вәлиев белән 1967 елдан бирле таныш. Әлбәттә, аның һәр адымын күзәтеп бара алмадым, шулай да юлларыбыз гел кисешә торды. Монысы – язмыштыр, дөресрәге, язмышның миңа елмаюыдыр.

Кайбер мәсьәләләрдә икеләнсәм, мин күңелдән генә Туфан абый һәм Разил белән киңәшеп алам, минем урында булсалар, алар ни эшләр, ни әйтер икән, дип уйлыйм. Парламент, депутатлар эшчәнлеге турындагы язмаларымда да шушы ике шәхеснең исемен еш телгә ала идем. Бу кемнәргәдер бик ошап та бетмәде. Туфан ага турында сүз әйтергә бик базмыйлар иде, ә менә: «Син гел Разил Вәлиев турында гына язасың», – дип үпкә белдерүчеләр булды. Нишлим инде, җәмәгать, Дәүсовет утырышларында авыз ачып бер җүнле сүз дә әйтә алмаганнар турында ни языйм?! Разил белән теләсә нинди темага рәхәтләнеп сөйләшә аласың. Үзеңне борчыган һәр сорауга җавап табасың.

Сөйкемле сөяк

Алмаз әйтүенчә, әле мәктәптә укыганда ук сабакташлары, хәтта укытучылар да Разилгә тартылган. Монда инде: «Разилнең сөйкемле сөяге бар», – дип кенә котыла алмыйсың. Кара әле, нинди матур безнең сөйләм теле! Бер уйлаганда, сөйкемле булуда сөякнең ни катышы бар инде! Әмма «сөйкемле сөяк» дип әйтүгә, күркәм холык-фигыльләрне үзенә туплаган кеше образы күз алдына килә дә баса. Шул «сөйкемле сөяк»тән һәркем үзенә шулай күркәм сыйфатлар эзли, аңа охшарга тырыша. Разилдә дә күп андый сыйфатлар. Шуларның берсе – мөгаен, тормышта башкалардан бер адым алдарак барырга омтылудыр. Чөнки арттан сөйрәлгән кешегә иярү, аңа охшарга тырышу мөмкин нәрсә түгел. Разил хәтта тау шуганда да иң текә җирдән беренче булып төшеп күрсәтә торган булган. Алмаз белән икәүләшеп мәктәптә «стенгәзит» чыгарганнар. Алмаз – бизәлеш өчен, Разил эчтәлек өчен җавап биргән. Әле мәктәпнең радиоузелын да җитәкләгән Разил. Кулына балта тотып, авылда бура бурап та йөргән. Инде өйләнеп, кеше фатирларында яши башлагач, һәр фатирга үзе ремонт ясый торган булган. Болар турында ишеткәнем юк иде әле. Әтисе Исмәгыйль абый колхоз председателе булса да, «персидәтел малае» булып үсмәгән Разил, үз тормышын үз көче белән корган.

Татарның да үз тормышы белән яшәвен теләде ул. Милли мәсьәләләрдә урамнарга чыгып, «Азатлык!» дип кычкырып йөрмәде, бәлки татар өчен кулыннан килгәнне эшләп барды. Милләт өчен кылынган гамәлнең олысы, кечесе юк иде аның өчен. Заманында, фикердәшләре белән яшьләргә татарча журнал таләп итеп, Камал театрында спектакль барганда листовкалар таратып йөрде. Кулдан язылган листовкаларның, өске ярустан ыргытылып, күбәләкләр кебек җилферди-җилферди тамашачы өстенә явуын бүген дә хәтерлим.

Бер елны Яңа Чишмә районының Сөлчәбаш авылына җыенга алып барды ул мине. Дәүсоветның матбугат үзәгендә эшләүче Җәүдәт Юнысов белән дә шунда таныштык. Җәүдәтнең абыйсы Фәрит – Разилнең дусты икән. Казанда укыганда бер фатирда яшәгән булганнар. Пенсиягә чыккач, Фәрит, туган авылы Сөлчәбашка кайтып, үзенә йорт салган, мәчетне, мәктәпне төзекләндергән, юлларга асфальт җәйдерткән. Һәм ел саен авыл җыены үткәрә башлаган. Берәүләр, авыллар бетә, дип зарланганда, Фәрит татар авылының гомерен озайтырга алынган. «Әнә шундый егетләр турында язарга кирәк», – дигән иде Разил. Мин аны сүзсез дә аңлаган идем инде. Сөлчәбашка кайткалый тордык, яза тордык. Кызганыч, Фәрит дус бакыйлыкка күчте. Дөньяда матур эз калдырып китте ул. Фәрит турында мин дусларга-танышларга, таныш түгелләргә дә җае чыккан саен сөйлим. Һәм сүзгә Разил Вәлиевне дә кушам. Чөнки ул да үз авылын карап тота.

Дипломат

Беренче эш итеп, манарасы кыйшайган мәчетне төзекләндергән, китапханә бинасына, мәдәният йортына да кулы тигән, урамнарга асфальт җәйдергән. Боларны миңа Алмаз сөйләде: «Ул нинди генә эшкә тотынса да, моның милләткә нинди файда китерәчәген уйлап тотына», – дигән иде Алмаз. Шәхсән үзем Разилнең инде менә ничә еллар буе мәктәп балалары арасында иҗат бәйгесе уздыруын беләм. Аның изге гамәлләрен саный башласам, кайберәүләр: «Акчасы күптер», – дип куя. Менә монысы безнең хөсетлегебез була инде. Хикмәт бит акчада түгел, ә дипломат булуда. Дипломат – грек сүзе, урталай бөкләнгән рәсми язма документ дигәнне аңлата. Разил халык гозерен хакимияткә җиткерә белә, аның сүзе үтә.

Алмаз һәр сайлауда Разил белән бергә йөрде. Аңа тавыш җыярга булышты. Ә Разил депутатлыкка партия исемлеге белән түгел, бер мандатлы округлардан уза иде. Бу – иң демократик ысул санала һәм син инде тавыш биргән халыкның ышанычын акларга тиеш буласың. Иң кызыгы: Разил бер үк округтан берничә тапкыр сайланды, димәк, депутат буларак халык ышанычын аклап барды дигән сүз. Хакимиятне эшләтә белү үзе – зур эш. Әмма Алмаз уенча, Разил кайвакытта артык дипломат булып китә торган булган. Моны гаепләп әйтми ул, чөнки һәр депутатның билгеле бер кысада эшләргә тиешлеген белә. Шуңа күрә кайвакыт үзе әйтергә ярамаган сүзләрне Разил Туфан абыйдан әйттерә иде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Мин аның депутат буларак эшчәнлеге турында артык җәелеп язып тормыйм. Ул җитәкләгән комитетны үзара, кыска гына итеп «милли комитет» дип йөртүебезне әйтсәм, Разилнең нинди уй-максат белән яшәве аңлашылыр. Аның бүлмәсеннән әдәбият-сәнгать әһелләре, милләтпәрвәрләр өзелмәде.

Ул депутатлыктан киткәч, үзләрен сәясәттә балык кебек йөзәм дип исәпләүчеләр: «Разил Вәлиев, шундый урында утырып, бәйсезлекне дә, телебезне дә саклап кала алмады», – дип сөйләнделәр. Башта аларга рәнҗегән дә идем. Инде менә хәзер рәхмәт әйтәсе килеп китте. Димәк, алар үзләре дә сизмичә, Разил туганның милли сәясәттә нинди зур эшләр башкарганын таныганнар булып чыга түгелме? Бөек үзгәрешләр чорында ул фидакарьләрнең алгы сафында булды. Суверенлык турында Декларацияне, Татарстан Конституциясен әзерләүдә, Төп Закон кысасында милләт кайгысын кайгырткан күпме законнар эшләүдә катнашты. Фикердәшләре белән бергә, күгәрчен тизәкләренә буяла-буяла, Дәүсовет бинасы гөмбәзенә менеп, Татарстан байрагын да кадады ул. Декларация кабул ителгән көнне Ирек мәйданында җыелган халыкка шатлыклы хәбәр җиткерүче дә Разил Вәлиев иде.

Шуңа күрә бөтен татар аны милләт йөген җигелеп тартучы дип кабул итте дә. Шөкер, сәяси сәхнәдән дә китмәде, иҗаты да туктап калмады Разил Вәлиевнең. Киресенчә, ниһаять, язарга вакыт күбрәк кала, дип шатланадыр да әле. Аны әледән-әле эшлекле киңәшмәләргә, төрле мәртәбәле җыеннарга дәшеп кенә торалар.

Бу дөньяда кемгәдер кирәк булып яшәүгә җитәме соң! Алмаз әйтмешли: «Ярый әле бу дөньяда татарның абруен күтәрерлек Ташлык егетләре бар!» Танылган шәхесләрнең нинди исем-дәрәҗәләр алуын санап та торасы юк. Мәсәлән, «Разил Вәлиев» диюгә үк, аның кем икәне һәркемгә аңлашыла. Бу үзе үк – зур бәхет. Юбилееӊ белән, Разил туган!

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

УКУЧЫ СҮЗЕ

КАДАКСЫЗ КАЗАНСУ КҮПЕРЕ

«Ватаным Татарстан» газетасында бик күп тарихи истәлекләр хакында кызыксынып укып барабыз. Мин дә Казансу күперен төзүдә катнашкан прораб, Кышлау авылы кешесе Галимулла абыйдан ишеткәннәрне язарга булдым әле.

Сугыш арты елларының берсендә авылның Мәннаф атлы кешесе агачтан бура буратырга күрше Кышлау авылыннан дүрт балта остасын чакырган. Шул бригаданың җитәкчесе – Галимулла абый. Эшкә барганда алар белән һәрвакыт туктап сөйләшә идем. Сүзне Галимулла абый башлап җибәрә иде. Көннәрдән беркөнне ул: «Энем, син бик авыр эшкә – колхоз рәисе вазыйфасына алынгансың икән. Бу авылның кешеләре бик эшчән, оештыра белсәң, эшең алга китәр», – диде.

Галимулла абый яшәгән Кышлау авылы балта осталарына бай иде. Алар күрше-тирә авылларда мәчетләр, күперләр төзегән. Чит төбәкләргә дә эшкә йөргән. Шулай бер көнне Галимулла абый Казансу аша безнең якта Кремль күпере дип аталган күпер төзелешендә катнашуын сөйләде.

Ул чорларда Казанда эшсезләр биржасы булган. Галимулла абый да үз бригадасы белән шунда барган. Анда төрле яклардан эш эзләп килгән кешеләр җыелган. Артельләргә кирәкле һөнәр ияләрен сайлап алып киткәннәр. Кешеләр дә үзләренә йорт, мунча, лапас, башка төрле корылмалар төзүчеләрне, гади эшчеләрне, мич чыгаручыларны, ат дагалаучыларны сайлаган. Көннәрнең берсендә бик чиста киенгән, галстук таккан берәү килеп, күпер төзүчеләр бармы, дип сораган. Ул Казансу күперен төзү өчен балта осталары эзли икән. Ләкин эшкә алынырга теләүче булмаган. Галимулла абый да шикләнгән. Ни өчен дигәндә, күперне бер кадак та кулланмыйча эшләргә кирәк булган. Көннәрдән беркөнне Галимулла абый янына бер кеше килеп:

– Син бу эш белән бик кызыксынасың, акчасы да күп икән, кабул итеп ал. Без аны эшләп чыгарбыз. Проекты да бар, җиңелрәк булыр, – дигән.

Галимулла абый исә, эшен белсәм дә, кешеләр белән идарә итү сәләте юк шул, ди. Ул кеше биржада бик яхшы балта осталары бар дип ышандырган. Син үзең кайсы якныкы дип сорагач, үзен Тау ягы кешесе дигән. Ул хәзерге Апас, Кайбыч, Кама Тамагы районнарының берсеннән булырга тиеш. Галимулла абый, эш бирүче – күпер төзү конторасының башлыгы белән танышып кайту өчен, Тау ягы кешесен дә алып бара. Аларны иң борчыган нәрсә – күперне кадаксыз эшләп чыгу. Иң авыр эш булып субай баганаларын ике метр җиргә кагып кертү була. Икенчесе – күпернең субайлары өстенә өслек билгеләү, аның ныклыгын тәэмин итүче ялгау төеннәрен беркетү. Шулар хәл ителсә, өскорманы корудан шикләнмиләр. Шулай итеп, Галимулла абый бу эшне кабул итеп ала. Ул төзү тәртибен өйрәнгән арада теге Тау ягы кешесе агач материаллар карарга китә. Шәм шикелле тигез, матур нарат агачларын Кәҗә бистәсе белән Кремль арасына кадәр тезеп куйганнар. Яхшы агачларны күреп сөенгәннәр. Агачлар тигез булганлыктан, балта белән юнып, ике башын да тигезләргә күп көч кирәкмәгән. Галимулла абый проект кәгазьләре, түләү мәсьәләсе буенча йөргәндә, Тау ягы кешесе биржадан балта осталарын алып килгән. Бервакытны төзелешкә барса, бик күп кешеләр агач юнып ята икән. Барлык агачларны эшкәртеп бетергәннәр. Биржага тагын барып, такта һәм брус яручылар сайлап алып кайткан. Агачларны югары менгезеп кую өчен стан, анда агач бүрәнәләрне тәгәрәтеп менгерү өчен күперчекләр ясаганнар. Үзенә күрә аерым бер төзелеш булган бу. Агачларны берьюлы берничә станда яра башлаганнар. Галимулла абыйның да эшнең барып чыгасына ышанычы арткан. Субайлар суга башлау вакыты җиткәч, су өстендә өстәмә күперчекләр эшләргә кирәк була. Шуннан соң яңадан биржага барып, субай кагу өчен таза егетләр сайлап алып кайталар. Проектта каралганча субайларны утыртканнар.

Ул эшләрне бетергәннән соң, өске өрлекләрне субай башларына «замоклар» ясап беркеткәннәр. Аннан соң өскормаларны ярган агачлардан проектта каралганча эшләп чыкканнар. Яңадан бик катлаулы эш – күперне боздан саклау корылмалары – «үгезләр» төзү эше башланган. Аларны эшләү ансат булмаган.

Күпернең алгы ягына бераз читкәрәк китеп, өч урынга өчәр субайдан тугыз багана ясап, аларның өстен су агып килү ягын кыскарак, икенчесен бераз озынрак, соңгысын тагын да биегрәк итеп, тимерләр белән ныгытып, агач брусларны тоташтырганнар. Күпернең ничә аралыгы булса, шуның кадәр бозваткычлар ясап чыкканнар. Кыскасы, күпер төзегән өчен бик яхшы бәя биреп, эшчеләргә бик күп акча түләгәннәр. Барысы да канәгать калган.

Өстәп шуны әйтәсем килә. Галимулла абый Сәмигуллин, гомеренең соңгы көненә кадәр җай чыккан саен, Тау ягы кешесен хөрмәткә лаек кеше дип искә ала иде. Проектта агачларны кадаксыз беркетүнең ике төрле беркетү төеннәре каралган булса да, ул кирәк урыннарда, катлаулылыгын искә алып, үз ысулларын кулланган. Безнең татар халкы арасында андый оста куллар бик күп булган. Йөрәге җитмәгән эшкә үзенең осталыгын кушып, иптәшләренең акылына, сәләтенә ышанып эшләгән эшләренең иң зурысы дип сөйли торган иде ул күпер төзүне.

Фәйзи ГАЛИЕВ.
Әтнә районы
Түбән Шашы авылы

Комбайн оттым

Барыгызны да яңа 2022 ел белән котлыйм. Нык сәламәтлек, озын гомер телим. Тормышларыгыз матур, юлларыгыз хәвеф-хәтәрсез, эшләрегез уң булсын. Газета тиражы кимемәсен. Өлкәнәйсәк тә, газетаны ташлыйсы килми әле. Хәзер инде заманча әбиләргә әйләндек. Кибеттә карта кулланып товар алабыз. Кулда телефон. Эш калдыргыч булса да, ярап тора үзе.

«Ватаным Татарстан» газетасында иң беренче лотерея 1988 елда уйнатылган иде. Шунда кухня комбайны оттым. Һаман да эшли, кулланабыз. Газеталарны яратып укыйм, ун төрлесен алдырам. Кайчак үзем дә сызгалаган булам. Күңел күтәренке бит. Авылыбыз төзек, матур. Һәрхәлдә, безнең Саба районында иске йорт, капкаларны тотмыйлар анысы. Юлларыбызга да асфальт түшәлгән. Шәһәрдән бер дә ким түгел.

Әнисә ГАТИЯТОВА.
Саба районы Олы Кибәче авылы

Таянычым

Мин 36 ел башлангыч сыйныфларда укыттым. Хәзер лаеклы ялда. «Ватаным Татарстан» газетасын 1968 елдан бирле алдырам. Һәрвакыт тулы вариантына язылам. Бик кызыксынып укыйм. Ул – минем сердәшем дә, таянычым да. Үзенең яктылыгын, җылылыгын биреп тора. Бу газетада бик үткен каләмле, барлык тармакларны да яктырта белүче журналистлар эшли. Барыгызга да бик зур рәхмәт. Газета чыгару – бик җаваплы, четерекле эш. Хаталар да китмәсен, иҗади эзләнүләрегез дә уңышлы булсын. Сезгә яңа үрләр, гаилә иминлеге телим.

Укучыгыз РОЗАЛИЯ.
Актаныш районы Такталачык авылы

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, Татарстан Республикасы Президенты Эшләре идарәсе гомуми бүлегенең элекке мөдире

Йосыпов Марат Якуп улының

вафат булуы сәбәпле, гаиләсе һәм якын туганнарының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, II чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисади үсеш һәм реформалар мәсьәләләре буенча даими комиссиясе (1999–2004 еллар) рәисе

ХӨСНУЛЛИН Мансур Мингали улының

вакытсыз вафат булуы сәбәпле, туганнары һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша. Мансур Мингали улы Хөснуллин турында якты хатирәләр безнең йөрәкләрдә мәңге сакланыр.

Спорт

Илдар Мөхәммәтҗанов

Җәлил турниры Казанга кайта

«Ватаным Татарстан» газетасы гамәлгә куйган, герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә үткәрелүче көрәш турниры 18–19 февраль көннәрендә Казанда узачак. Бүгенге вазгыятьне исәпкә алып, республиканың көрәш федерациясендә ярышны башкалада уздыру турында карар кабул ителде.

Муса Җәлил бәйгесенең соңгы елларда Казанда уздырылганы булмады. Турнирны берничә тапкыр рәттән Чаллы кабул итте, аннары ул Әлмәткә күчте, соңгы елларда көрәшчеләр Биектау, Зәй һәм Актаныш келәмендә бил алышты. Былтыр Минзәләдә узган турнирда командалар беренчелеген Әлмәт егетләре отты. Чаллы батырлары – икенче, Теләче көрәшчеләре өченче булды.

Үз категорияләрендә җиңүче булып Илсур Гыймадетдинов (Кукмара), Илназ Миңмуллин (Балтач), Искәндәр Мортазин (Әлмәт), Ленар Садыйков (Чаллы), Ренас Кәлимуллин (Теләче), Раил Сәлахетдинов (Кукмара), Илнар Галимов (Алабуга), Эльдар Хәмитов (Чаллы), Муса Галләмов (Теләче) һәм Сергей Павлик (Зәй) танылды.

Дзюбасыз гына киттеләр

Россия футболының иң шау-шулы уенчысы Артем Дзюба «Рубин»га күчмәячәк. «Зенит» клубының генераль директоры Александр Медведев әйтүенчә, һөҗүмче Санкт-Петербургта кала. Казан командасы исә, футбол сезонының язгы өлешенә әзерләнү өчен, Төркиягә юл тотты.

Санкт-Петербург клубы белән килешүе тәмамланып килүче Дзюбаның «Рубин»га күчү мөмкинлеге турындагы хәбәрләр декабрьдә пәйда булган иде. 33 яшьлек һөҗүмченең Казан командасы баш тренеры Леонид Слуцкий белән дуслыгын, «Зенит»та исә остазлар белән мөнәсәбәтләре бик үк җылы булмавын телгә алдылар. Имеш-мимешләр бер ай буе футбол җәмәгатьчелегенең игътибарын җәлеп итеп торды. Сөйләшүләрнең ахырына якынлашып, инде килешү төзергә җыенулары турында мәгълүмат чыкты. Бу атнада исә Санкт-Петербург ягы «уенчының 100 процентка үзләрендә каласын» әйтте. Дзюбага Казанга китәргә комачау иткән сәбәпләр арасында футболчының күп кенә ширкәтләр белән килешүе барлыгы да телгә алына. Бу исә – зур суммалар дигән сүз. Дзюба Россия чемпионатында 17 очрашуда чыгыш ясап, 10 туп кертте һәм 4 нәтиҗәле пас бирде.

Шулай итеп, «Рубин», сезонның язгы өлешенә әзерләнү өчен, Төркиягә Дзюбасыз гына юл тотты. Казан клубы соңгы вакытта очколар белән сөендерә алмаса да, социаль челтәрләрдә тамашачының күңелен күрергә тырыша. Әйтик, Төркиягә җыенга киткән һөҗүмчеләр исемлегендә «100 процент Дзюба түгел» дигән язу да бар.

Җылы якка киткән уенчылар арасында Михаил Костюков, Мицуки Сайто һәм Монтассар Талби да юк. Костюковка сезон ахырына кадәр аягын дәваларга туры киләчәк. Казанда нибары 3 мәртәбә уен кырына чыккан япон егете Сайто, ниһаять, туган иленә кайтып китте. Талби исә Тунис җыелма командасы белән Африка милләтләре кубогында чыгыш ясый.

Яңа уенчыларга килгәндә, моңа кадәр «Спартак», «Арсенал» һәм «Химки»да чыгыш ясаган ярымсакчы Александр Ломовицкий Казан клубы белән декабрьдә килешү имзалаган иде. Сакчылар Илья Вахания, Егор Тесленко, ярымсакчы Михаил Стрельник, капкачы Евгений Спиряковны Төркиягә сынап карар өчен алып баралар. Ошатсалар, килешү имзалау ихтималы бар. Исемлек моның белән генә чикләнмәячәк, әлбәттә. Матбугат чаралары «Рубин»ның ЦСКА уенчысы Константин Кучаев белән сөйләшүләр алып баруын хәбәр итә. Капкачы Иван Коноваловны исә Шотландиягә кодалыйлар.

Төркиядә Казан командасы 3 җыен һәм 9 матч уздырырга ниятли. Россия чемпионатында исә беренче очрашу 28 февральдә әлеге дә баягы «Зенит»ка каршы булыр дип көтелә.

ҖИҢЕЛ ПАР БЕЛӘН!

Саба районында яшәүче 30 яшьлек Руслан Миңнегуловны Казан, Чаллы, Әлмәт шәһәрләренә, Кукмара, Мамадыш, Лаеш кебек районнарга мунчага чакыра башлаганнар. Юк, юынырга түгел, башкаларны чабындырырга. Спорт мәктәбендә эшләүче тренерның яңа һөнәре ни дәрәҗәдә төшемле һәм кызык булып чыккан?

Руслан Миңнегуловның пар остасына әйләнүе уйламаганда килеп чыккан. Интернетта мунчада чабучылар курсы турындагы игълан кызыксыну уяткан. Кызык бит, ә нигә тәвәккәлләп карамаска? Саба районындагы Миңгәр авылында урнашкан ял итү комплексына барып, чабындыручы булып эшләргә теләвен белдергән ул. Укып кайтам дигәч, әлбәттә, ризалашканнар. Курслардан соң беренче булып туганнарын, энекәшен, тормыш иптәше Алинәне чабындыра. Аннары махсус программа төзеп, ял комплексында эшли башлый. Өйләргә дә чакыргалыйлар үзен. Руслан әйтүенчә, чабыну очсыз түгел, шуңа күрә беренче чиратта акчасы булган, сәламәтлеге турында борчылган, үз кадерен белгәннәр кызыксына. Алар арасында ирләр генә түгел, хатын-кызлар да бар. Шулай ук гайрәтле бабайлар да каршы түгел, сабыйлар да чабындырганны ярата. Шуңа күрә егеткә төрле яшьтәге кешеләр белән очрашырга туры килә. Әлбәттә, бу урында: «Хатын-кызларны чапканга ирләре каршы килмиме, көнләшмиләрме?» – дип сорамыйча булдыра алмадым. «Ел буе эшләп арыган хатын-кызларга, киресенчә, мунчада чабынып чыгуны ирләре ял буларак тәкъдим итә. Гаиләләре белән дә чабам. Өлкән апалар да чакыра. Моның бернинди ояты да юк. Алар мине җан һәм тәннәренә сихәт бирүче табиб кебек кабул итә. Мунчаның сәламәтлекнең нигезе икәнен аңлыйлар. Хатыным да көнләшми», – ди Руслан Миңнегулов.

Ул бүген инде иректе чабучы, акчасын түләсәләр, республиканың төрле төбәгенә чыгып китәргә риза. Кемдер өенә, кемдер җәмәгать мунчасына да чакыра. Сабада хезмәте өчен 1,5 мең сум алса, ерак юлга чыкканда, бәя 6 меңгә җитә. Әлбәттә, монда юл, чабыну өчен кирәк-ярак чыгымнары да керә. Уртача алганда 3–4 меңгә төшә. Мунчаны бит аны төрлечә керергә була. Печән матрасларына ятып, артыш, ак чыршы себеркеләре белән, төрле үләннәр иснәп. Кыскасы, юрганыңа карап, аягыңны сузасың. Тик бу әлеге хезмәттән байлар гына файдалана дигән сүз түгел.

– Авылда пар остасы белгечлеген бик аңлап бетермиләр. Акча түләп, кеше чакыртып чабыну күпләрнең башына сыймый. Эссе су сибәм дә үзем чабынам дип уйлыйлар. Тик мунча хаталанганны яратмый. Районда тагын берничә егет пар остасына укып кайтты. Казанда мунчалар еш ачыла. Шәһәрдә халык күп йөри. Кайберләрендә еллык заказ язып куелган. Мунча культурасы буенча шәһәрдә үсеш бар. Тик әле бездә дөрес итеп мунча керүчеләр сирәк, – ди Руслан.

> **Белеп торыгыз!**
> • Мунчаны атнасына ике тапкыр керергә мөмкин. Көнаралаш керсәң дә зыянлы түгел.
> • Эсседән суыкка күчкәндә, организмыгызны тыңлый белегез. Югыйсә салкын тиюе бар.
> • Мунчада элек салкын тию, сулыш юллары, тире авыруларын дәвалаганнар.

Эссе бирден дә туйганчы чабындың түгел. Белгеч әйтүенчә, шәп мунча кыздырудан гына тормый.

– Мунчаны күп дигәндә 80 градуска кадәр җылытырга була. Кайбер кешеләр аны колагы пешкәнче кыздырып ялгыша. Иң кулае – 60–70 градус. Кызу мунчада организмда кислород күләме кискен кимеп, кеше үзен начар хис итә башлый. Шуңа күрә дымлы булуы кирәк. Мунча кызуы һәркемгә җитәрлек булсын. Пардан да, себеркедән дә күп нәрсә тора, – ди оста. – Исерткеч белән керәсе түгел. Бу хакта алдан ук кисәтеп куям. Ни өчен дигәндә, йөрәккә көч киләчәк. Ашап керү дә киңәш ителми. Гадәттә, бездә халык корсагын тутырып керә. Ашказаны буш булганда организмнан токсиннар тизрәк чыга. Кан басымы уйнаган, тире авырулары булганнарга да чабынудан тыелырга кирәк. Шулай ук пар остасының арымаган булуы да мөһим. Чапканда эссегә түзеп ятарга киңәш итмим. Онытылып ял итә белгәндә генә файдасы тиячәк.

Миллек пешерүнең дә үз серләре бар. Гадәттә, без каен яки имән себеркесен ләгәндәге кайнар суга тыгып куябыз. Алай ярамый, ди Руслан. Дөрес итеп парландыру өчен, аны йә берничә сәгать алдан салкын суга тыгарга яки җылымса суда тотып, пакетка төреп, ләүкәдә 20–30 минут тотарга кирәк. Менә шуны истә тотканда, мунча себеркесе бик яхшы парланачак. Башны салкында тоту өчен, ак чыршы каплый икән. Коела торган миллек тә мунча тәмен бозачак. Шуңа күрә бәясе кыйммәтрәк булса да, себеркеләрне Казандагы махсус кешедән сатып ала икән. Вакытын белеп, дөрес итеп җыярга кирәк. Шомыртныкы, әремнеке кирәкме, артыш, каен, имән себеркесеме... – сайлар өчен мөмкинлекләр күп хәзер.

> **МУНЧА КЕРГӘНДӘ ЕШ ОЧРЫЙ ТОРГАН ХАТАЛАР**
> ✓ Кызуда мөмкин кадәр озаграк утырырга тырышу.
> ✓ Коры мунчаны дымландырмау.
> ✓ Башны салкында тотмау.
> ✓ Миллекне кайнар суда пешекләү.
> ✓ Керүгә эссе су сибеп, ләүкәгә менеп яту.
> ✓ Мунчага кергәч утыру, ягъни башны эсседә, аякны салкында тоту. Горизонталь формада яту кирәк.
> ✓ Корсак тутырып ашап керү.

– Беренче тапкыр чабынган кешеләр дә булды. Башта берсе, эссе, чабынмыйм, дип каршы килсә дә, соңыннан рәхмәт әйтте. Кайбер кеше эссе салмаска куша, кемгәдер кызу кирәк. Эшне җылынудан башлыйбыз. Моның өчен 10–15 минут вакыт кирәк. Ташка тәмле исләр сибәбез. Шуннан соң ләүкәгә менәргә мөмкин. Юынган арада үлән чәе эчеп, тамак ялгап та алалар. Кыскасы, кемдер – ярты сәгать, кемдер озак итеп чабынып юынырга мөмкин. Монысы кешенең хәленә карап. Кайберәүләр кар белән ышкына. Елга ярында урнашкан мунчаларда юынганда коенып алучылар да бар. Ташка эфир майлары сибеп ис чыгару яклы түгелмен. Мунча керүчеләргә үлән, себерке исләре иснәтү әйбәт. Ак чыршы, артыш, донник, әрем, бөтнек исләре дә яхшы, – ди ул.

Спорт мәктәбендә чаңгычылар әзерләгән тренер төп эшен дә ташларга җыенмый. Ни өчен дигәндә, икесе дә күңеленә якын. Әле аның чабыну ярышларында катнашу хыялы да бар. Шуңа күрә алга таба яңа ысулларны барларга исәбе. Киләчәктә районда заманча мунча төзисе килә икән. Әлегә акчаны шулай йөреп эшләргә туры киләчәк.

Сәрия МИФТАХОВА

ИҢ ЗУР ХЫЯЛГА ЮЛ

Соклану

Еллар алмашкан чорда, һәркем үз тормышына анализ ясый, үз-үзенә хисап тота. Кем өчендер ел гадәти булгандыр, кемгәдер югалту-табышлары белән истә калгандыр. Кемнәргәдер ел авыр, мәшәкатьле булып тоелгандыр. Тик язмам героена гына түгел.

...Ноябрьдә сәламәтлеге чикле спортчылар арасында Теләчедә үткән Татарстан беренчелегенә үткән кул көрәше ярышында җиңүчеләр арасында авылдашым Илназ Мәхмүтовны күреп, аеруча сөендем. Күз алдыбызда үскән бу егетнең соңгы ике ел ярым гомере гел көрәштән торса да, сер бирми, сынатмый. 2019 елның 5 августында Балтач – Арча арасында булган коточкыч авариядән соң ул кичергән операцияләрне, реабилитация курсларын, бер адым алга, ике адым артка чигенешләрне, алар белән бәйле кичереш-сызлануларны искә алсаң, егетнең сабырлыгына, ныклыгына сокланып гаҗәпләнә торган.

Хәтерләсәгез, тугызынчы сыйныфны тәмамлагач, укырга кирәкле документлар тапшырып кайтышлый юл һәлакәтенә очраган Илназ турында бер язган идек инде. Түләүле ярдәм-курслар күп кирәк чак иде шул, шөкер, көнләпсәгатьләп катлауланган язмышына битараф калмаучылар бихисап булды. Юкса авария вакытында Илназда күзгә күренгән бердәнбер җәрәхәт – башындагы яра гына була. Аны теккәч, кинәт эче авырта башлый. УЗИ эчәклекләренә зыян килгән дип күрсәтә. Операциягә керер алдыннан Илназ, аякларымны тоймыйм, ди. Шулай тоела гынадыр дигән өметләр акланмый. Кызганычка, аркасындагы гематома аякларына зыян китерә... Алга таба исә озак вакыт хәрәкәтсез булган егеткә бер-бер артлы башка диагнозлар да куела: «непроходимость кишечника» дип тә операция ясыйлар, аягында барлыкка килгән тромбларны да дәвалыйлар. Шөкер, әлеге операцияләр уңышлы чыга: 15 килога ябыккан Илназ акрынлап «сафка кайта». Шул көннән инде бүгенгәчә Илназ бер минут хәрәкәтсез тормый дисәң дә, ялгыш булмас. Ул үзе дә, әти-әнисе Илдар белән Альфира да бик тырыша. Һәр мөмкинлекне кулдан ычкындырмыйча, түләүсез һәм түләүле бик күп тернәкләндерү үзәкләрендә булдылар, өйләрендә дә махсус җайланмалар белән туктаусыз шөгыльләнделәр.

– Безгә авыр чакта бик күп кешеләр ярдәм итте. Авылдашлар, танышлар, бер белмәгән кешеләр акчалата да, киңәш-табыш белән дә күп булышты. Газетадагы язма да бик вакытлы булды. Ул чакта югалып калмаска, нык булырга ярдәм иткән һәр кешегә без гомеребез буе рәхмәтле, – ди әнисе Альфира. – Аерым рәхмәтләребез улыбызның дусларына, сыйныфташларына. Алар аны ташламады, ялгыз калдырмады.

...Үткән ел көтмәгәндә бу йорт ишеген районда кул көрәше тренеры булып танылган Фагыйль Гайнетдинов шакый. Илназ белән бушлай шөгыльләнергә теләвен әйтә. Риза булмыймы соң Илназ! Бик теләп, бик тырышып өйрәнә башлый. Беренче нәтиҗәләр озак көттерми: тәүге ярышта ук Татарстан күләмендә беренче урынны ала!

– Россия күләмендә Орел шәһәрендә үткәрелгән ярышка да барган идем, анда ир-атлар арасында көрәшергә туры килде, урын ала алмадым. Быел Татарстан күләмендә Теләчедә үткәрелгән ярышта беренчелекне алдым. Хәзер мин Яңгулга Ранил абый Сафиуллинга тренировкага йөрим. Илкүләм ярышка әзерләнәбез, – ди шушы көннәрдә генә чираттагы дәваланудан кайткан Илназ. Һәм: «Миңа ышаныч күрсәтеп, минем белән шөгыльләнгән Фагыйль абый белән Ранил абыйга бик зур рәхмәт», – дип өсти.

Илназ ирешкән уңышлар әле болар гына түгел: ул, өйдә укып, урта мәктәп тәмамлый. Казанда 4 ай укып, кул белән идарәгә көйләнгән машинада өйрәнеп, имтиханнарын уңышлы тапшырып, «права» ала. Бүген машинада йөри. Чавал авыл хуҗалыгы техникумына читтән торып укырга кереп, икътисадчы-бухгалтер белгечлеген үзләштерә.

Иң зур хыялың да чынга ашсын, уңышлар сиңа, авылдаш...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6943 данә
Гомуми тираж – 18156 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 203

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+